ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10 сентябрь 2021 ел № 5966

Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында» 2019 елның 31 октябрендәге 5631 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Башкарма комитетның «Муниципаль программаларны эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 5326 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасы турында 2019 елның 31 октябрендәге 5631 номерлы карарына ( Башкарма комитетның 2020 елның 9 гыйнварындагы 4 номерлы, 2020 елның 26 июнендәге 3086 номерлы, 2020 елның 10 декабрендәге 6726 номерлы, 2021 елның 3 мартындагы 1440 номерлы, 2021 елның 1 апрелендәге 2238 номерлы, 2021 елның 12 июлендәге 4694 номерлы карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә 2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәрендә физик культура һәм спортны үстерү муниципаль программасын тормышка ашыру буенча чараларны финанслауны шәһәр бюджетында «Физик культура» 1101 һәм «Массакүләм спорт» 1102 бүлекләре (бүлекчәләре) буенча каралган акчалар хисабына 1 657 426,1 мең сум күләмендә тәэмин итәргә: 2020 ел – 547 453,5 мең сум, 2021 ел – 581 451,00 мең сум, 2022 ел – 528 521,6 мең сум.»;

2) «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләмнәре һәм | Финанслау чыганаклары (мең сум) | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | Тормышка ашыру чорында барлыгы |
| | Муниципаль бюджет | 508 930,4 | 549 055,66 | 528 521,6 | 1 586 507,66 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| чыганаклары | Федераль бюджет | 29 000,0 | - | - | 29 000,00 |
| | Республика бюджеты | 9 523,1 | 32 395,34 | - | 41 918,44 |
| | Барлыгы | 547 453,5 | 581 451,00 | 528 521,6 | 1 657 426,1 |

- 6 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 бүлек. Программаны ресурс белән тәэмин итү

Программа чараларын тормышка ашыру өчен бюджет акчаларын 1 657 426,1 сум күләмендә файдалану күздә тотыла: 2020 ел – 547 453,5 мең сум, 2021 ел – 581 451,00 мең сум; 2022 ел – 528 521,6 мең сум.»;

- 8 бүлекне кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Башкарма комитетның
2021 елның 10 сентябрендәге
5966 номерлы карарына
кушымта

8 бүлек. «2020-2022 елларга Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә физик культура һәм спортны үстерү» программасының максатлары, бурычлары, нәтиҗәләрен бәяләү индикаторлары һәм программа чаралары буенча финанслау

| № т/б | Төп чараларның исеме | Үтәүчеләр | Төп чараларны үтәү сроклары | Ахыргы нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары, үлчәү берәмлекләре | Индикаторларның зурлыгы | | | | Финанслау чыганакларын күрсәтеп, мең сум | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | 2019 ел | 2020 ел | 2021 ел | 2022 ел | 2020 год | 2021 год | 2022 год |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
| Программаның максаты: Җәмгыятьнең төрле катлауларын физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүгә җәлеп итү | | | | | | | | | | | |
| Бурычның исеме: Халыкны физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүгә җәлеп итү дәрәҗәсен арттыру. | | | | | | | | | | | |
| 1. | Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында физик культура һәм массакүләм спортны үстерү, физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы спорт чаралары үткәрү мәсьәләләре буенча муниципаль хокукый актлар эшләү һәм аларны раслау | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт белән системалы шөгыльләнүче халыкның халыкның гомуми санында өлеше, % | 47,9 | 49,7 | 50,0 | 51,5 | | | |
| 2. | Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидлар арасында шәһәр физкультура-сәламәтләндерү, комплекслы чаралар, фестивальләр, спорт бәйрәмнәре үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Физик культура һәм спорт белән даими шөгыльләнүче сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле затлар һәм инвалидларның халыкның әлеге категориясендәге гомуми санында өлеше, % | 19 | 19,5 | 20,5 | 21 | | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 3. | Халыкның төрле яшь төркемнәре арасында «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексын популярлаштыруга юнәлдерелгән чаралар оештыру һәм үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Хезмәткә һәм оборонага әзер» (ГТО) Бөтенроссия физкультура-спорт комплексы нормативларын үтәгән халык өлеше, ГТО нормативларын үтәүдә катнашкан халыкның гомуми санында өлеше, % | 35 | 35,5 | 36,5 | 37 | | | |
| 4. | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, кубоклар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Спорт төрләре буенча чемпионатлар, беренчелекләр, массакүләм ярышлар саны, берәмлек | 20 | 20 | 20 | 20 | Муниципаль бюджет | | |
| | Төрле яшь категорияләре арасында спорт төрләре буенча массакүләм ярышлар үткәрү | | | | | | | | 2344,1 | 1486,4 | 1486,4 |
| 5. | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында спорт төрләре буенча ярышлар, халык-милли уеннарын һәм көч сынашуларын үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Сабан туе» халык бәйрәме кысаларында ярышлар саны, берәмлек | 27 | | 27 | 27 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 0,0 | 1000,0 | 1000,0 |
| 6. | «Спорт сөюче Чаллы» хезмәткәрләр спартакиадасын үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Спорт сөюче Чаллы» спартакиадасы кысаларында үткәрелгән спорт төрләре буенча ярышлар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 34,8 | 49,5 | 49,5 |
| 7. | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар үткәрү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | «Физик мөмкинлекләре чикле кешеләр арасында Яр Чаллы шәһәре Хакиме Кубогы»на ярышлар саны, берәмлек | 8 | 8 | 8 | 8 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 30,4 | 31,8 | 31,8 |
| Бурычның исеме: Югары казанышлар спортын үстерү. Спорт резервын әзерләүнең нәтиҗәле системасын булдыру | | | | | | | | | | | |
| 8. | Шәһәр Хакиме стипендияләре түләү юлы белән физик культура һәм спорт өлкәсендә талантлы укучыларга ярдәм күрсәтү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким стипендиясен алучы балалар һәм яшүсмерләр саны, кеше. | 10 | 10 | 10 | 10 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 120,0 | 120,0 | 120,0 |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 9. | Югары һөнәри осталыклары өчен муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләренә шәһәр Хакиме премиясен бирү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Хаким премиясен алган муниципаль физик культура һәм спорт учреждениеләре хезмәткәрләре саны, кеше | 15 | 15 | 15 | 15 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 390,6 | 390,6 | 390,6 |
| 10. | Халыкара һәм Россия ярышларында югары спорт казанышлары өчен спортчыларга бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | ел саен | Россия, Европа, Дөнья чемпионатлары, Олимпия уеннары, Бөтендөнья Универсиадасы җиңүчеләре һәм призерлары саны, кеше | 40 | 11 | 20 | 20 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 624,9 | 1 233,9 | 1 233,9 |
| 11. | Түбәндәге спорт төрләре буенча спорт әзерлеге программасын гамәлгә ашыру: баскетбол, волейбол, җиңел атлетика, спорт ориентлашуы, дзюдо, каратэ киокусинкай, кикбоксинг, йөзү, синхрон йөзү, нәфис гимнастика, велоспорт, спорт гимнастикасы, теннис, тимераякта узышу спорты, футбол, велоспорт (шоссе), регби, билбаулы көрәш, грек-рим көрәше, армреслинг, көрәш, йөзү, тхэквондо, күп стильдәге каратэ, батутта сикерү, АКД, спорт акробатикасы, бокс, авыр атлетика, чаңгы узышлары, бию спорты, ат спорты, спорт туризмы, өстәл теннисы, бадминтон, җилкәнле спорт, фехтование, пауэрлифтинг, алкалы хоккей, тимераякта фигуралы шуу, шахмат | 17 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе | ел саен | Гомуми тренерлар саныннан югары һөнәри белемле тренер кадрлар өлеше, % | 92 | 93 | 94 | 95 | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | Хезмәт күрсәтү сыйфатына карап төркемнәрнең факттагы тулылыгы, % | 100 | 100 | 100 | 100 | 484365,7 | 544467,63 | 524209,4 |
| | | | | Конкурсларда, фестивальләрдә, күргәзмәләрдә, ярышларда катнашучы шөгыльләнүчеләр саны, гомуми укучылар саны буенча, %, шул исәптән:<br>- муниципаль;<br>- региональ;<br>-федераль, халыкара | 20<br>10<br>1 | 30<br>20<br>1 | 30<br>20<br>1 | 30<br>20<br>1 | | | |
| | | | | Укыту программаларының үтәлү проценты, % | 100 | 100 | 100 | 100 | | | |
| | | | | Контингент сакланышы, % | 88 | 88 | 88 | 88 | | | |
| 12. | Муниципаль спорт мәктәпләре хоккей спорт командаларының | 1 муниципаль | 2020-2021 годы | Муниципаль спорт мәктәпләре хоккей спорт | | 80 | 80 | | Республика бюджеты | | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатында катнашуы | физик культура һәм спорт учреждениесе | | командаларының хоккей буенча Татарстан Республикасы чемпионатында һәм (яки) хоккей буенча Россия Федерациясе чемпионатындагы катнашкан уеннары саны | | | | | 1 224,4 | 1 492,3 | |
| 13. | Спорт мәктәпләрен спорт инвентаре, җиһазлар, экипировка белән җиһазландыру | 16 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе | 2020-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыра торган, спорт җиһазлары, экипировкалар һәм инвентарь сатып алу өчен субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | 16 | 16 | | Республика бюджеты | | |
| | | | | | | | | | 4 090,9 | 3 320,2 | |
| 14. | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру белән бәйле чараларны тормышка ашыру | 1 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе 1 | 2020-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыра торган, спортчыларның рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларында катнашулары өчен субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | 1 | 1 | | Республика бюджеты | | |
| | | | | | | | | | 992,0 | 2939,7 | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 10,0 | 29,40 | |
| 15. | Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә физик культураны, массакүләм спортны үстерү, рәсми физкультура-сәламәтләндерү һәм спорт чараларын үткәрүне оештыру өчен шартлар тудыру белән бәйле чараларны тормышка ашыру, муниципаль йөкләмәне үтәүне тәэмин итүнең финанс күләмен арттыру өлешендә | 3 муниципаль физик культура һәм спорт учреждениесе | 2020-2021 еллар | Яр Чаллы шәһәрендә спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыра торган, субсидия алган муниципаль учреждениеләр саны | | 1 | 2 | | Республика бюджеты | | |
| | | | | | | | | | 3225,67 | 24643,14 | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | | 246,43 | |

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 16. | Заманча спорт-сәламәтләндерү комплексы, махсуслаштырылган спорт корылмасы төзелеше | Башкарма комитетның физик культура һәм спорт идарәсе | 2020 ел | Дәүләти-шәхси партнерлык катнашында төзелгән спорт-сәламәтләндерү комплекслары, махсуслаштырылган спорт корылмалары, берәмлек | | 1 | | | Федераль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 29 000 | | |
| | | | | | | | | | Муниципаль бюджет | | |
| | | | | | | | | | 21 000 | | |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева